Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең
Болгар-1 авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы карары

03 август 2026 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2026 елның 3 августында 18 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәсе белән түбәндәге «Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кашир авыл җирлеге бюджетына 2025 елда 147 500 сум күләмендә кергән гражданнарның үзара салым акчалары "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кашир авыл җирлегенең Болгар-1 авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2024 елның 22 ноябрендә кабул ителгән 5 нче номерлы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кашир авыл җирлегенең Болгар-1 авылында 2025 елга гражданнарның үзара салымын кертү турында» 6 нчы номерлы карарларына нигезләнеп, торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерүгә (массакүләм чаралар өчен бина территориясен төзекләндерү) билгеләнгән әлеге акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалау һәм халыкка бирүне тәэмин итүче башка инженер корылмаларны проектлау, төзү һәм ремонтлауга (су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, материал сатып алу)» юнәлдерү белән килешәсезме? соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 94 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 52 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 52 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлегенең Болгар-1 авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кашир авыл җирлеге бюджетына 2025 елда 147 500 сум күләмендә кергән гражданнарның үзара салым акчалары "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кашир авыл җирлегенең Болгар-1 авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында" 2024 елның 22 ноябрендә кабул ителгән 5 нче номерлы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кашир авыл җирлегенең Болгар-1 авылында 2025 елга гражданнарның үзара салымын кертү турында» 6 нчы номерлы карарларына нигезләнеп, торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерүгә (массакүләм чаралар өчен бина территориясен төзекләндерү) билгеләнгән әлеге акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә «су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалау һәм халыкка бирүне тәэмин итүче башка инженер корылмаларны проектлау, төзү һәм ремонтлауга (су белән тәэмин итү системасын ремонтлау, материал сатып алу)» юнәлдерү белән килешәсезме? турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Болгар-1 авылы, Үзәк урамы, 65А йорты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Кәшер авыл җирлеге башлыгы А.Ш. Садриев